КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 сентябрь г.Казань № 874

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган Шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 547 нче; 2016 ел, 9 август, 547 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 39 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 206 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлекнең 5.2 нче бүлекчәсендә:

5.2.27 нче пунктта:

беренче абзацта «чикләрен» сүзен төшереп калдырырга, татарча текстта «юл буенча полосалары» дигән сүзләрне «юл буенча полосаларын» дигән сүзләргә алыштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автомобиль юлларының юл буе полосалары турындагы нигезләмә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана.»;

5.2.34 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2.34. Автомобиль юлының юл буе полосалары чикләрендә капиталь төзелеш объектлары, юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар, юл сервисы объектлары төзү, аларны реконструкцияләү, реклама конструкцияләре,

мәгълүмат щитлары һәм күрсәткечләр урнаштыру автомобиль юлы хуҗасының язма формадагы ризалык кәгазе булганда рөхсәт ителә. Бу ризалык кәгазендә мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр һәм шартлар булырга тиеш.

Әгәр дә капиталь төзелеш объектын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителсә, мондый объектны автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру буенча документлар аны раслаганга кадәр автомобиль юлы хуҗасы белән килештерелә. Бу ризалык кәгазендә мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр һәм шартлар булырга тиеш. Шул ук вакытта бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә объект төзүгә, аны реконструкцияләүгә рөхсәт кәгазен алу таләп ителми.

Автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә капиталь төзелеш объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру буенча документлар белән автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә объектлар төзүгә, аларны реконструкцияләүгә ризалык бирү турында яки мондый объект төзүне, аны реконструкцияләүне килештерүдән баш тарту турында хәбәр итү тәртибе һәм вакытлары, территорияне планлаштыру буенча документлар, шулай ук мондый баш тарту өчен нигезләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

Автомобиль юлларына тоташтырыла торган 10 мең кв.метрдан артык булган гомуми мәйданлы стационар сәүдә объектлары транспорт чараларын куеп тору урыннары һәм тукталышлар урыннары, шулай ук килү юллары, чыгу юллары белән һәм, аларга автомобиль юлыннан керү мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, килеп тоташу юллары белән җиһазландырылырга тиеш. Автомобиль юлы башка автомобиль юлына килеп тоташканда, килү юлларының һәм чыгу юлларының тизлекне арттыру-киметү полосалары булдырылырга һәм, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында, автомобиль юлын төзекләндерү элементлары белән җиһазландырылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин